**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702097, ОГРН 1061672000037, ИНН/КПП 1638004978/163801001

# РЕШЕНИЕ
# КАРАРЫ

**02 сентябрь, 2020 ел** **№ 54-5**

**Тәтеш муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 2019 елның 25 февралендәге 39-8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендәге муниципаль хезмәт турындагы” Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы Муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы кодексы” Татарстан Республикаксы законы, “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Уставы” нигезендә, Тәтеш муниципаль районы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Тәтеш муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 2019 елның 25 февралендәге 39-8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 3 абзацындагы “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” сүзләреннән соң “муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рәисе” сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 2.1 бүлекнең 2.1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«2.1.1. Муниципаль хезмәт вазифасы - муниципаль вазифаны биләүче затның яисә муниципаль берәмлекнең сайлап алу комиссиясе, җирле үзидарә органы вәкаләтләрен башкаруны тәэмин итүче билгеләнгән вазифалар даирәсе белән муниципаль берәмлек уставы нигезендә барлыкка килүче, җирле үзидарә органындагы, муниципаль берәмлекнең сайлап алу комиссиясе аппаратындагы вазифа»;

1.3. 2.1 бүлекнең 2.1.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«2.1.3. Муниципаль берәмлекнең сайлау алу комиссиясе аппараты, җирле үзидарә органының штат расписаниесен төзү һәм раслау өчен Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәтләр вазифалары реестрында каралган, муниципаль хезмәт вазифалары атамалары кулланыла»;

1.4. 3.1 бүлекнең 3.1.2 пунктын түбәндәге редакциялә бәян итергә:

«3.1.2. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, җирле үзидарә органының эшчәнлекне техник тәэмин итү буенча вазыйфаларын башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазифасын биләмиләр һәм муниципаль хезмәткәр булып саналмыйлар»;

1.5. 3.5 бүлекнең 3.5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«3.5.1. Муниципаль хезмәткәргә, муниципаль хезмәт үтү белән бәйле, ярамый:

1) Түбәндәге очракта, муниципаль хезмәт вазифасын биләргә:

а) Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына яки Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазыйфасына сайлану яисә билгеләнү, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләнгән очракта;

б)муниципаль вазыйфага сайлану яисә билгеләнү ;

в) профессиональ союз органында түләүле сайланулы вазыйфага сайлану, шул исәптән муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында, җирле үзидарә органында оштырылган беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органында;

2) Түбәндәге очраклардан тыш, коммерцияле яисә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу:

а) Түләүсез нигездә сәяси фирка, профессиональ союз органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында, җирле үзидарә органында оштырылган беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә яисә съездда(конференциядә) яки башка төр иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милек ияләре товарищлыкларының гомуми җыелышларында катнашу;

б) Түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма (сәяси фирка, профессиональ союз органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында, җирле үзидарә органында оштырылган беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә яисә съездда(конференциядә) яки башка төр иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милек ияләре товарищлыкларының гомуми җыелышларында катнашудан тыш) белән идарә итүдә, муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы Кодексының 16.1 маддәсе нигезендә билгеләнгән тәртибе буенча алынган яллаучы (эш бирүче) вәкиле ризалыгы белән катнашу;

в) Муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә “Татартан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы” Ассоциациясендә, башка төр муниципаль берәмлек берләшмәләрендә, шул исәптән аларның идарә органнарында тәкъдим итү;

г) Муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә идарә итү органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә тәкъдим итү;

д)Федераль законда каралган башка очраклар;

3) шәхсән яисә ышанычлы затлар аркылы эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнү;

4) муниципаль берәмлек сайлау комиссиясендә, җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән вәкил яисә өченче затлар эшләре буенча вәкил булу;

5) физик һәм юридик затлардан вазыйфаи вәкаләтләрне башкару яисә вазыйфаи хәле белән бәйле рәвештә бүләкләр кабул итү (бүләкләр, акчалата бүләкләр, ссудалар, хезмәтләр, күңел ачуларны, ял итүләрне, транспорт чыгымнарын түләү һәм башка төр түләүләр). Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, беркетмәле чаралар, хезмәт командировкалары һәм башка төр рәсми чаралар белән бәйле рәвештә кабул ителгән бүләкләр, муниципаль милек дип танылa һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, акт буенча Россия Федерациясе Гражданлык кодексы белән билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенә, җирле үзидарә органына тапшырыла. Муниципаль хезмәткәр, беркетмәле чара, хезмәт командировкасы яисә башка төр рәсми чара белән бәйле рәвештә кабул иткән бүләген тапшыргач, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары билгеләгән тәртиптә, сатып алу мөмкинлегенә ия;

6) физик һәм юридик затлар чаралары хисабыннан, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе, җирле үзидарә органының башка муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе, җирле үзидарә органнары һәм шулай ук дәүләт хакимияте органнары һәм чит ил дәүләтләре җирле үзидарә органнары, халыкара һәм чит ил коммерцияле булмаган оешмаларның килешеп үзара нигезендә гамәлгә ашырылучы командировкалардан тыш, командировкаларга бару;

7) материаль-техник, финанс һәм башка төр тәэмин итү чаралар, башка муниципаль милек, вазыйфаи вәкаләтләрне башкару белән бәйле булмаган максатларда куллану;

8) федераль закон игезендә конфеденциаль характердагы мәгълүматларны яисә вазыйфаи взкаләтләрен башкарганда билгеле булган хезмәт мәгълүматларын, муниципаль хезмәт белән бәйле булмаган максатларда куллану;

9)муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе, җирле үзидарә органы эшчәнлеге һәм аларның җитәкчеләренә кагылышлы ачыктан-ачык фикерләр, бәяләр әйтү;

10) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башлыгының язмача рөхсәтеннән башка чит ил дәүләтләре, халыкара оешмалар, шулай ук сәяси фирка, башка төр иҗтимагый берләшмәләр һәм дини берләшмәләр бүләкләре, мактау һәм махсус исемнәр кабул итү ;

11) вазыйфаи хәлнең өстенлекләрен сайлау алды агитациясе өчен, шулай ук референдум сораулары белән бәйле агитацияләрдә куллану;

12) үзеңнең вазыйфаи хәлеңне сәяси фирка, дини һәм башка иҗтимагый берләшмә мәнфәгатьләрендә куллану, шулай ук муниципаль хезмәткәр сыйфатында, күрсәтелгән берләшмәләргә карата ачыктан-ачык мөнәсәбәтеңне белдерү;

13) җирле үзидарә органнарында, башка төр муниципаль органнарында сәяси фирка, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләр структуралары оештыру яисә күрсәтелгән структураларны оештыруда ярдәм күрсәтү ;

14) хезмәт бәхәсен җайга салу максатыннан вазыйфаи вәкаләтләрне башкаруны туктату;

15) Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган чит ил коммерцияле булмаган хакимиятнеке булмаган оешмалар органнары, попечительлек һәм күзәтчелек советы, идарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре составына керү;

16) чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыклары булмаган затлар чаралары хисабына финансланган түләүле эшчәнлек белән яллаучы (эш бирүче) вәкиленең язмача рөхсәтеннән башка шөгыльләнү;

1.6. “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлегендәге муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне киләсе эчтәлектәге 3.5 бүлеге белән тулыландырырга:

**«3.5[I]. Муниципаль хезмәткәрнең түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу**

3.5.1[I] муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коммерцияле булмаган оешмалар(сәяси партия, профессиональ союз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында ясалган беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы,муниципаль берәмлекнең саулау комиссия аппараты, съездларда (конференцияләрдә) катнашу, иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, күчемсез милек милекчеләр ширкәте белән идарә итүдән тыш) белән бушлай идарә итүдә катнашу өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкилнең рөхсәте белән генә гамәлгә ашырыла.

3.5.2$^{1}$. Муниципаль хезмәткәрнең түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу мәнфәгатьләр каршылыгына яисә мәнфәгатьләр каршылыгы туу мөмкинлегенә китерергә тиеш түгел.

3.5.3$^{1}$. Муниципаль хезмәткәрнең түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуга рөхсәт турындагы гаризасы язмача, муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы Кодексының 2.1 кушымтасы нигезендәге форма буенча муниципаль хезмәткәрне яллаучы(э бирүче) вәкиле исеменә төзелә.

3.5.4$^{1}$. Гариза, түләүсез нигездә коммерцияле оешма белән идарә итүдә катнашу чарасының планлаштырылган вакытына кадәр муниципаль берәмлекнең сайлау комисиясе аппараты, җирле үзидарә органының кадрлар хезмәтенә тапшырыла.

3.5.5$^{1}$. Гаризаларны теркәү, кадрлар хезмәте тарафыннан, муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы Кодексының 2.2 нче кушымтасы нигезендә, гаризаларны теркәү журналына кергән көннән башлап гамәлгә ашырыла. Гаризаларны теркәү журналының битләре нумерацияләнгән, тегелгән һәм печать белән беркетелгән булырга тиеш.

3.5.6$^{1}$. Гаризаның күчермәсе, дата, гариза теркәвенең номеры, әлеге гаризаны теркәгән кадрлар хезмәте затының вазифасы һәм фамилиясе, инициаллары күрсәтелгән килеш, муниципаль хезмәткәргә, гаризаларны теркәү журналына кул куйдырып тапшырыла.

3.5.7$^{1}$. Кадрлар хезмәте, гаризаның теркәлүен, алдан каралуын һәм түләүсез нигездә, коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуның мөмкинлеге яисә мөмкин тугеллеге турында дәлилләнгән бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыра. Дәлилләнгән бәяләмәне әзерләгән вакытта, кадрлар хезмәте гаризаны тәкъдим итүче муниципаль хезмәткәрнең ризалыгы белән, аның белән әңгәмә үкәрү һәм анардан язмача аңлатмалар алу мөмкинлегенә ия.

3.5.8$^{1}$. Дәлилләнгән бәяләмә эчендә булырга тиеш:

1) Кадрлар, оештыру-техник, финанс, материаль-техник һәм коммерцияле булмаган оешмалар мөнәсәбәтендә башка төр сораулар, шул исәптән әлеге коммерцияле булмаган оешманың аерым гамәлләрен яисә билгеле бер төр эшчәнлеген гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү белән бәйле сораулар буенча карар кабул итү өчен муниципаль хезмәткәрнең вәкаләтләрен анализлау;

2) Муниципаль хезмәткәрнең түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашкан очракта мәнфәгатьләр каршылыгы туу мөмкинлеген анализлау.

3.5.9$^{1}$. Гариза һәм дәлилләнгән бәяләмә, гариза теркәлгәннән соң 7 эш көне эчендә эш бирүче вәкиленә юллана.

3.5.10$^{1}$. Гаризаны карау һәм дәлилләнгән бәяләмә нәтиҗәләре буенча эш бирүче вәкиле түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) муниципаль хезмәткәргә түләүсез нигездә, коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу өчен ризалык бирергә;

2) муниципаль хезмәткәргә түләүсез нигездә, коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу өчен ризалык бирмәскә;

3) Муниципаль хезмәткәрнең гаризасы белән дәлилләнгән бәяләмәсен кабат тикшерү максатыннан муниципаль берәмлекнең сайлап алу комиссиясендә оештырылган, Тәтеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу Комиссиясенә юлларга

3.5.11$^{1}$. Карарның 10 өлешендәге 2 пунктында каралган, муниципаль хезмәткәрнең түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашкан очракта мәнфәгатьләр каршылыгы туу мөмкинлеге булу карар кабул итүгә нигез булып тора.

3.5.12[1]. Карарның 3.5.10 өлешендәге 3 пунктында каралган очракта, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе, гариза белән дәлилләнгән бәяләмәне, күрсәтелгән комиссиягә юлланылган көннән алып, җиде көн эчендә карый.Гариза белән дәлилләнгән бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе, муниципаль хезмәткәрнең түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашкан очрагында муниципаль хезмәкәрнең мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге яисә килеп чыкмавы турында карар кабул итә.

3.5.13[1] карарның 3.5.12 өлешендә каралган, карар кабул ителгән көннән алып, өч көн эчендә, яллаучы(эш бирүче) вәкиле муниципаль хезмәткәргә түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарү итүдә катнашуга рөхсәт бирү яисә бирмәве турында карар кабул итә.

3.5.14[1]. Кадрлар хезмәте, яллаучы(эш бирүче) вәкиле тарафыннан кабул ителгән, карарның 3.5. 13 өлешендә яисә 3.5.10 өлешенең 1,2 пунктларында каралган, ике карарның берсен кабул иткән көннән алып, өч көн эчендә, муниципаль хезмәткәргә язма формада, гаризалар теркәү журналында кул куеп яисә кабул ителгән карар турында мәгълүмат почта элемтәсе аша юллана. .

3.5.15[1]. Гариза, дәлилләнгән бәяләмә һәм гаризаны карау нәтиҗәләре белән бәйле башка төр материаллар хезмәткәрнең шәхси эшенә теркәлә"

1.7. 3.8 бүлекнең 3.8.14 пунктындагы "башка дисциплинар җәза" сүзтезмәсен "башка җаваплылык чаралары" сүзтезмәсенә;

1.8. 4.1 бүлекнең 4.1.3. пунктындагы 6 бүлекчәсендә "мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы" сүзләрен "шәхси (персональ) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ" сүзләренә алыштырырга;

1.9. 6.2 бүлекнең 6.2.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«6.2.2. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе җирле үзидарә органын бетерү белән бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр белән Хезмәт килешүен өзгәндә яисә муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе җирле үзидарә органы хезмәткәрләре штатын кыскартканда, муниципаль хезмәткәргә, оешманы бетерү яисә оешма хезмәткәрләре штатын кыскарту белән бәйле рәвештә эштән азат ителгән очракта хезмәткәрләр өчен хезмәт законы тарафыннан билгеләнгән гарантияләр тәкъдим ителә.»;

1.10. 6.3 бүлекнең 6.3.6. пунктындагы "ә стажның дәвамлылыгы һәм айлык түләүләр, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә муниципаль хезмәткәргә билгеләнгән шундый ук мәгънәдә исәпкә алына" сүзләре "ә сыйныф чины өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгели торган норматив хокукый актында билгеләнгән мәгънәдә исәпкә алына." сүзләре белән алыштырырга ";

1.11.8.4 бүлекнең 8.4.2. пунктын киләсе редакциядә бәян итергә:

«8.4.2. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси эше 10 ел дәвамында саклана. Муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәттән азат ителгәннән соң, шәхси эше, соңгы муниципаль хезмәт эше урыны буенча муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең җирле үзидарә органы архивында саклана»;

1.12. 8.4 бүлекнең 8.4.3. пунктын киләсе редакциядә бәян итергә:

«8.4.3. Муниципаль хезмәткәр үз хезмәт вазыйфасын биләгән муниципаль берәмлектәге сайлау комиссиясенең җирле үзидарә органы бетерелгәндә, хезмәткәрнең шәхси эше, ликвидацияләнгән муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең җирле үзидарә органы эшчәнлеге тапшырылган муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең җирле үзидарә органына саклауга тапшырыла..».

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы башлыгы урынбасары Е.Г.Курковка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**башлыгы** **Р.Х. Сафиуллов**